| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 02 нче апрель Ульянково авылы № 5

**Ульяновка авыл җирлегендә территорияне төзекләндерү һәм санитар чистарту икеайлыгы уздыру турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «территорияләрне чистарту буенча экологик икеайлык үткәрү турында» 2019 ел, 25 март, 136 нчы карарына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсенә, Ульянково авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм санитар карап тоту кагыйдәләренә таянып, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү, Ульянково авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм санитар торышын яхшырту максатларында:

1. Ульянково авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен 2019 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр төзекләндерү һәм җыештыру буенча икеайлык үткәрергә.
2. Икеайлыкны үткәрү комиссиясе составын расларга (1 нче кушымта).
3. Ульянково авыл җирлеге территориясендә икеайлыкны үткәрү чаралары планын расларга.(2 нче кушымта).
4. Халык арасында төзекләндерү икеайлыгын үткәрү буенча оештыру-аңлату эшләре алып барырга.
5. Учреждение һәм оешма җитәкчеләренә, шәхси йорт хуҗаларына җирлек территориясен төзекләндерү һәм җыештыру буенча чаралар планын үтәү өчен кирәкле чаралар күрергә кирәк.
6. Территорияләрне төзекләндерү һәм санитар җыештыру буенча атналык санитар көн (җомга) билгеләргә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.
8. Әлеге карарны Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Ульянково авылҗирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Ф.А.Сундурова

Ульянково авыл җирлеге
Башкарма комитетның
2019 ел, 02 апрель, 5 номерлы
Карарына 1 нче кушымта

ИКЕАЙЛЫКНЫ ОЕШТЫРУ, ҮТКӘРҮ БУЕНЧА ҺӘМ АНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕН ЯСАУ КОМИССИЯ СОСТАВЫ

1. Сундурова Ф.А. - Җирлек башлыгы, комиссия рәисе
2. Челнокова Н.А. – Ульянково мәктәбе директоры, (килешү буенча)
3. Кузенкова О.А. – Корноухово ФАПының шәфкать туташы, (килешү буенча)
4. Пулялина Н.Г. – Ульянково авыл мәдәният йорты методисты, (килешү буенча)
5. Сундуров Ю.И. – Ульянково авыл җирлеге Советы депутаты, (килешү буенча).

Ульянково авыл җирлеге
Башкарма комитетның
2019 ел, 02 апрель, 5 номерлы
Карарына 2 нче кушымта

# ИСӘП
## икеайлык үткәрү буенча чаралар
## Ульянково авыл җирлеге территориясен 2019 елга төзекләндерү һәм җыештыру буенча

| Чараның исеме | Үтәү срогы | Үтәү өчен җаваплы |
|---|---|---|
| Җирлек территориясен төзекләндерү мәсьәләсе буенча барлык торак пунктларда гражданнар җыеннары үткәрергә | Апрель | Авыл Җирлек башлыгы Сундурова Ф.А. |
| Үзебезнең һәм биналарга якын-тирә учреждениеләр, оешмалар, уртак файдалану урыннарын төзекләндерү буенча өмә оештырырга һәм үткәрергә. | 21, 28 апрель | оешма-учреждениеләр җитәкчеләре |
| Санкцияләнмәгән чүплекләрдән каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару буенча эшләрне оештырырга һәм үткәрергә | апрель | Авыл Җирлек башлыгы Сундурова Ф.А. |
| Учреждение һәм оешма җитәкчеләренә, шәхси йорт хуҗаларына биналарның һәм шәхси йортларның фасадларына кирәкле косметик ремонт ясарга, коймаларны һәм палисадникларны тиешле кыяфәткә китерергә, су агып төшүче канауларны һәм йорт янындагы территорияләрне чүп-чардан арындырырга. | май | оешма-учреждениеләр җитәкчеләре, шәхси йорт хуҗалары |
| Ульянково һәм Корноухово авылларында агач утырту буенча «Яшел Яз-2019» Бөтенроссия экологик өмәсе үткәрергә. | 5 май | Авыл Җирлек башлыгы Сундурова Ф.А. |
| Җирлек территориясендә урнашкан учреждение һәм оешма җитәкчеләренә җир китерүне оештырырга, үз карамагындагы учреждениеләр янында чәчәк түтәлләре һәм клумбалар корырга кирәк | Апрель-май | оешма-учреждениеләр җитәкчеләре |
| Учреждение һәм оешма җитәкчеләренә, шәхси йорт хуҗаларына ведомство карамагындагы учреждениеләр һәм йортлар янында коры агач кисүне һәм куакларны кисүне оештырырга | Апрель, май | оешма-учреждениеләр җитәкчеләре, шәхси йорт хуҗалары |
| Һәйкәл тирәсен җыештыру, чәчәк утырту өчен клумбалар әзерләү буенча өмә үткәрергә | Май | бюджет хезмәткәрләре, җирле халык |
| Торак пунктларның зиратларын җыештыру буенча өмә үткәрергә | 5, 12 май | авыл җирлеге депутатлары |
| Балалар мәйданчыкларын төзекләндерү һәм чистарту | Апрель-май | Авыл Җирлек башлыгы Сундурова Ф.А. |
| "Безнең урамда яз" фотоконкурсын оештырырга. Иң яхшы фоторәсемнәрне Ульянково авыл җирлеге сайтында бастырып чыгарырга була | Май | Сәркәтип Кормаенкова С.Г. |
| Җирлек территориясендә электр тапшыру линиясенең тирәген агарту | май | бюджет хезмәткәрләре |